**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм фән министры**
**_____________ И.Г.Һадиуллин**
**«19» ноябрь 2025 нче ел**

# Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә укучылар өчен туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздыруның эчтәлек элементлары һәм төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсен тикшерү таләпләре кодификаторы

# Кодификатор
## контрольных измерительных материалов для проведения государственной итоговой аттестации по образовательным программам основного общего образования 2026 года по родному (татарскому) языку для обучающихся-татар школ с русским языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясенең эчтәлек элементлары һәм укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр кодификаторы

Туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясенең эчтәлек элементлары һәм укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр кодификаторы (алга таба – кодификатор) – дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының структурасын һәм эчтәлеген билгели торган документларның берсе. Кодификатор төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсен тикшерү таләпләре һәм эчтәлек элементларының билгеле бер системага салган исемлеген тәшкил итә. Кодификаторда һәр объектның коды язылган.

Кодификатор ике бүлектән тора:

1 нче бүлек – туган (татар) телдән төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсен тикшерү таләпләре исемлеге;

2 нче бүлек – туган (татар) телдән төп дәүләт имтиханында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге

Кодификаторда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләргә, белем бирү программаларына кертелмәгән әзерлек дәрәҗәсе таләпләре чагылыш тапмый.

## 1 нче бүлек. Туган (татар) телдән төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсен тикшерү таләпләре исемлеге

*1 нче таблица*

| Бүлек | Таләп коды | Туган (татар) телдән төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсен имтихан эше биремнәрендә тикшерә торган таләпләр |
|---|---|---|
| 1 | | ***Телдән һәм язма сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләрен камилләштерү (телдән һәм язма аралашуның заманча чаралары ярдәмендә сөйләшү һәм тыңлап аңлау, уку һәм язу, аралашу)*** |
| | 1.1 | Татарча уку күнекмәләрен һәм укылган материалның эчтәлеген аңлау күнекмәләрен камилләштерү, шул исәптән текстның төп фикерен, төп төшенчәләрен билгели, дәлилли һәм тәэсирлек чараларын бәяли белү |
| | 1.2 | Максатка һәм аралашу даирәсенә ярашлы төрле текстлар яза белү (бирелгән сорауга дәлилле җавап, сочинение, аннотация, план (тезислы планны да кертеп), гариза, мәгълүмати сорау һ.б.) |
| 2 | | ***Татар теленең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен файдалану*** |
| | 2.1 | Сәнгатьлелек чараларының төп төрләрен тану һәм тасвирлап бирү (метафора, фразеологизм, синоним, антоним, омоним) |

| **Бүлек** | **Таләп коды** | **Туган (татар) телдән төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсен имтихан эше биремнәрендә тикшерә торган таләпләр** |
|---|---|---|
| 3 | | ***Тел, аның берәмлекләре һәм категорияләре турында фәнни белемнәрне камилләштерү һәм системалаштыру; тел катламнары һәм берәмлекләренең үзара бәйләнешен аңлау; тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерү*** |
| | 3.1 | Сүз төркемнәре һәм аларның формаларын мәгънәләре һәм төп грамматик билгеләре буенча тану |
| | 3.2 | Исем, сыйфат, алмашлык, сан, рәвеш һәм аларның морфологик билгеләрен танып белү |
| | 3.3 | Фигыль, сыйфат фигыль, хәл фигыль һәм аларның морфологик билгеләрен тану |
| | 3.4 | Бәйлек, кисәкчә һәм теркәгечләрне тану, кисәкчәләрнең мәгънәви төсмерләрен билгеләү |
| | 3.5 | Ымлыкларны тану, ымлыкларның грамматик үзенчәлекләрен билгеләү |
| 4 | | ***Сүзне төрлечә анализлау, сүзтезмә һәм җөмләгә синтаксик анализ ясау, шулай ук текстны төрле яклап тикшерү күнекмәләрен формалаштыру*** |
| | 4.1 | Сүзнең аваз составын билгеләү, сүзне иҗекләргә дөрес итеп бүлү, авазларга характеристика бирү |
| | 4.2 | Сүзнең лексик мәгънәсен, стилистик төсмерләрен, күпмәгънәле сүзнең мәгънәләрен, кулланылыш өлкәсен билгеләү, синоним, антонимнар сайлау |
| | 4.3 | Мәгънәви, грамматик һәм ясалыш анализы нигезендә сүзне морфемаларга бүлү |
| | 4.4 | Мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәренә морфологик анализ; аларның синтаксик функциясен билгеләү |
| | 4.5 | Җөмлә составындагы сүзтезмәне аера белү, сүзтезмәдә ияртүче һәм иярүче сүзне билгеләү, сүзтезмәнең төрен билгеләү |
| | 4.6 | Җөмләгә синтаксик анализ ясау, мөстәкыйль сүз төркемнәренең синтаксик ролен билгеләү |
| | 4.7 | Текстка анализ ясау һәм текстның төп билгеләрен аера белү, текстның темасын, төп фикерне, ачкыч сүзләрне, микротеманы билгеләү, текстны абзацларга бүлә белү, текстның композицион элементларын белү |
| | 4.8 | Сөйләм стильләрен, текстның билгеле бер стильгә каравын билгели, шулай ук билгеле бер сөйләм стиленә караган текст яза белү |
| | 4.9 | Бәйләнеш төрләрен, текстта җөмләләрнең мәгънәви, лексик һәм грамматик бәйләнеш чараларын билгеләү, шулай ук аларны файдалануның урынлылыгын һәм максатка ярашлылыгын ачыклау |

| Бүлек | Таләп коды | Туган (татар) телдән төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсен имтихан эше биремнәрендә тикшерә торган таләпләр |
|---|---|---|
| 5 | | ***Әдәби телнең төп нормаларына (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуацион, стилистик), сөйләм этикеты нормаларына ия булу; телдән һәм язмача фикер формалаштырганда, сөйләмдә тел нормаларын куллану тәҗрибәсе булдыру*** |
| | 5.1 | Гади һәм катлаулы җөмләләрдә, туры сөйләмдә, цитата китергәндә, диалогта тыныш билгеләрен кую кагыйдәләрен файдалану |
| | 5.2 | Хәзерге татар әдәби теленең төп орфоэпик кагыйдәләрен саклау, акцентологик нормалар нигезендә сүздә басымның урынын билгеләү |
| | 5.3 | Исем, сыйфат, алмашлык, сан, фигыль формаларын үзгәртү |

**2 нче бүлек. Туган (татар) тел буенча төп дәүләт имтиханына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге**

*2 нче таблица*

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| **1** | | ***Фонетика*** |
| | 1.1 | Авазлар |
| | 1.2 | Сүзгә фонетик анализ |
| | 1.3 | Аваз һәм хәреф |
| | 1.4 | Фонетиканың графика һәм орфография белән бәйләнеше |
| **2** | | ***Лексика һәм фразеология*** |
| | 2.1 | Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күпмәгънәле сүзләр; сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе |
| | 2.2 | Антонимнар. Омонимнар. Синонимнар |
| | 2.3 | Кулланылышы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы. Килеп чыгышы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы |
| | 2.4 | Фразеологик әйтелмәләр |
| | 2.5 | Сүзгә лексик анализ |
| **3** | | ***Сүз төзелеше, сүз ясалышы*** |
| | 3.1 | Сүз төзелеше |
| | 3.2 | Сүз ясалу ысуллары |
| | 3.3 | Сүзнең төзелешен тикшерү |
| | 3.4 | Сүз ясалышы турындагы белемнәрне орфографиядә куллану |

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| **4** | | ***Грамматика. Морфология*** |
| | 4.1 | Сүз төркемнәре |
| | 4.2 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре |
| | 4.3 | Ярдәмче сүз төркемнәре |
| | 4.4 | Сүзгә морфологик анализ |
| **5** | | ***Грамматика. Синтаксис*** |
| | 5.1 | Сүзтезмә һәм аның төрләре |
| | 5.2 | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре |
| | 5.3 | Җөмлә. Җөмләнең грамматик (предикатив) нигезе. Баш кисәкләр (ия, хәбәр). Иярчен кисәкләр |
| | 5.4 | Бер составлы һәм ике составлы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр |
| | 5.5 | Тиңдәш кисәкләр. Эндәш сүзләр. Кереш сүзләр. |
| | 5.6 | Кушма җөмлә. Кушма җөмлә төрләре. |
| | 5.7 | Тезмә кушма җөмлә |
| | 5.8 | Иярченле кушма җөмлә |
| | 5.9 | Туры һәм кыек сөйләм |
| | 5.10 | Гади һәм кушма җөмләгә синтаксик анализ |
| | 5.11 | Текст. Текстның төп билгеләре (мәгънәви бөтенлек, эзлеклелек, тәгәлләнгән булуы). |
| 6 | | ***Орфография*** |
| | 6.1 | е, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 6.2 | о-ы, ө-е хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 6.3 | в хәрефенең дөрес язылышы |
| | 6.4 | ъ-ь билгеләренең дөрес язылышы |
| | 6.5 | къ-гъ, к-г авазларын дөрес язу кагыйдәләре |
| | 6.6 | э хәрефенең дөрес язылышы |
| | 6.7 | Сүз азагындагы [п] һәм [к], [къ] авазларының дөрес язылышы |
| | 6.8 | Дифтонгларның дөрес язылышы |
| | 6.9 | Сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләре |
| | 6.10 | -ия, -ие, -ль гә беткән алынма сүзләрнең дөрес язылышы |
| | 6.11 | Баш хәрефләрне язу кагыйдәләре |

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| | 6.12 | Саннарның дөрес язылышы |
| | 6.13 | Инфинитивның дөрес язылышы |
| | 6.14 | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы |
| | 6.15 | Тезмә, парлы, кушма сүзләрнең дөрес язылышы |
| | 6.16 | Кушымчаларның дөрес язылышы |
| | 6.17 | Орфографик принциплар |
| **7** | | ***Пунктуация*** |
| | 7.1 | Тыныш билгеләре. |
| | 7.2 | Гади җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 7.3 | Туры сөйләм һәм диалогта тыныш билгеләре |
| | 7.4 | Кушма җөмләдә тыныш билгеләре |
| **8** | | ***Сөйләм*** |
| | 8.1 | Тел һәм сөйләм. Сөйләм төрләре (телдән һәм язмача). |
| | 8.2 | Стильләр һәм сөйләм төрләре |
| | 8.3 | Сөйләм эшчәнлеге продукты буларак текст. Тема, проблема, идея. Төп һәм икенчел мәгълүмат |
| | 8.4 | Текстның функциональ-мәгънәви типлары: хикәяләү, тасвирлау, фикерләү |
| | 8.5 | Текстны анализлау |
| | 8.6 | Төрле стильдәге һәм сөйләм төрендәге текстлар төзү |
| **9** | | ***Тел нормалары*** |
| | 9.1 | Орфоэпик нормалар |
| | 9.2 | Лексик нормалар |
| | 9.3 | Грамматик нормалар (морфологик нормалар) |
| | 9.4 | Грамматик нормалар (синтаксик нормалар) |
| **10** | | ***Татар сөйләменең матурлыгы*** |
| | 10.1 | Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы |
| | 10.2 | Лексика һәм фразеологиянең тәэсирлелек чаралары |
| **11** | | **Төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны тикшерү** |
| | | Уку төрләре (танышу, эзләнү, өйрәнү, карап чыгу максаты белән уку), уку әсбабы, ММЧ һәм Интернет ресурслар кебек башка мәгълүмат чыганаклары белән эшләү алымнары |